**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

№ 5 24 февраль2015 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе Этика кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына 29.11.2014 № ПУ -1100 үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә һәм Аксубай муниципаль районының Савруш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт өлкәсендәге мәсьәләләрне җайга салуны алга таба камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы турында»21.04.2011 ел, № 8 карары белән расланган Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертергә.

2. Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтенә керүче Россия Федерациясе гражданы кодекс нигезләмәләре белән танышырга һәм үз хезмәт эшчәнлеген башкарганда, шул исәптән «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрен кулланып, аларны үтәргә тиеш».

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubayevo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Савруш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Г.Кузьмин.